11 нче декабрь, 2015 ел №2



# МӘКТӘБЕМ МИНЕМ

**Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы**

Яңа елга багышланган махсус чыгарылыш!

## Хуш киләсең, Яңа ел!



Әйлән-бәйлән уйный ап-ак карлар,
Яңа елны көткән көннәрдә.
Җемелдиләр ак йолдызлар мени,
Якты йолдыз кебек төннәрдә.

Күтәрелеп күктә очкан чакта,
Ак йолдызлар көйләр чыгара.
Ак энҗеләр күргәч күңелләрдә,
Өшер өчен юктыр, юк чара.

Ап-ак кына энҗе бөртекләре,
Әйлән-бәйлән, уен уйныйлар.
Һәр туасы яңа матур көнгә,
Яңа елда бәхет юрыйлар.

Ак карларың, ак хисләрең белән,
Хуш киләсен безгә **Яңа ел**!
Әйлән-бәйлән уйный ап-ак карлар,
Яңа елга җәеп яңа юл!

**Гусева Виктория, 9 М:**

*Мин Яңа елны яратам, чөнки дуслар һәм туганнар белән бәйрәм итәсең, күңел ачасың. Яңа елга әдәби китаплар бүләк итүләрен телим.*

**Бикмуллина Сәмирә, 1 Б:**

*Яңа елны Кыш бабай, Кар кызы, матур чыршы булганга һәм дусларым белән бәйрәм иткәнгә яратам. Кыш бабайның курчак алып килүен көтәм.*

**Афанасьева Оля, 5 Г:**

*Яңа елны гаилә белән җыелып бәйрәм иткәнгә, бүләкләр биргәнгә яратам.*

**Халматова Гөлназа, 3 В:**

*Мин Яңа елны каршыларга яратам. Бу иң матур бәйрәм. Кыш бабайдан курчак сорадым.*

**Петров Данил, 3 Г:**

*Яңа елга Кыш бабайдан уенчыклар сорадым. Бу бәйрәмне түземсезлек белән көтәм.*

**Наумова Диана, 5 Г:**

*Яңа ел бәйрәмен аның бүләкләре өчен яратам. Яңа елда сәламәтлек, озын гомер телим.*



## “Дөньяның бәллүр йөрәге”




5-6 нчы декабрь көннәрендә балалар һәм яшүсмерләр иҗаты буенча үткәрелүче “Дөньяның бәллүр йөрәге” дип аталган халыкара фестиваль-конкурс булып узды. Бу фестиваль-конкурсның максаты булып, төрле милләт вәкилләренең гореф-гадәтләрен, сәнгатен хөрмәт итү тора. Мәктәбебезнең бер төркем җырчы һәм биюче укучылары, барабанчы кадетлары, ике телдә чыгыш ясап, “Театраль сәнгать” номинациясендә I нче дәрәҗә лауреат исемен яуладылар. Солистлардан Абдуллина Зәринә һәм Вәлеева Диләраләрнең җырга талантлы булулары һәркемне сокландырды. Бәйгедә катнашкан укучыларыбызны чын күңелдән тәбрик итәбез. Аларга уңышлар, яңа җиңүләр телибез.


**Галиев Рүзәл, 4 нче В сыйныфы укучысы**



Күренекле татар әдибе Хәсән Туфанның тууына 115 ел.



Хәсән Туфан 1900 нчы елның 27 нче ноябрендә Казан губернасы Чистай өязе Иске Кармәт авылында крестьян гаиләсендә унынчы бала булып туа. Иске Кармәт мәктәбенә йөрү белән бергә, күрше чуаш авылындагы мәктәптә бер ел русча да укый. Уфадагы “Галия” мәдрәсәсендә белем ала. 1918-1923 нче елларда Урал һәм Себер мәктәпләрендә укыта, үзлегеннән белемен тирәнәйтә. 1924 нче елда Туфан Казанга килә һәм шунда төпләнеп кала. Башта Бишбалта бистәсендә балалар укыта, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә, радиокамитетта эшли. 1924 нче елда «Кызыл Татарстан» газетасында Х. Туфанның беренче шигыре басыла."Алга барышлый", "Иртәләр житте исә", "Гөлләр инде яфрак яралар", "Үзеңә бүләк итәсе иде", "Чәчәк сибелә жилдә", "Агыла да болыт агыла", "Сиңа", "Ромашкалар", "Тамчылар ни диләр", "Тургай нигә дәшми", "Әйткән идең", "Кая шулай ашыгасың, йөрәк", "Сүз кушасы килә талларга" шигырьләрендә аның ижаты тирән лирик моң һәм киң фәлсәфи аһәң белән байый. 1966 нчы елда Хәсән ага Туфанга "Сайланма әсәрләр"е өчен Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе бирелде.




**Шәйхиева Илнара, 4 В**

**сыйныфы укучысы**



## Калфаклы сандугач



*2015 нче елның 30 нчы октябрендә Сара Садыйкова исемендәге “Калфаклы сандугач” татар җыры һәм музыка уен-коралларының VIII төбәкара ачык фестиваль-конкурсы үтте. Безнең мәктәптән “Вокал-соло” номинациясендә Әхмәдуллина Саида (3Б), Хөснетдинова Алия (4Г), Вәлеева Диләрә (11А) катнаштылар. Алар үзләренең җырга осталыклары, талантлары белән башка чыгыш ясаучылардан аерылып тордылар һәм жюриның югары бәясенә ия булдылар. Әхмәдуллина Саида (җит.Урманчеева Р.Э.) II урынга, Вәлеева Диләрә (җит. Рәхиева Ә.Н.) III урынга лаек булдылар. Котлыйбыз! Аларга алдагы чыгышларында да уңышлар телибез.*



**Мәрданова Айгөл, 9 нчы Г сыйныфы укучысы**



## *Киләчәккә билет*

*2015 нче елның 16 нчы октябрендә "Киләчәккә билет" республика конкурсының муниципаль иҗади эшләр этабында 7 нче ЕМ сыйныфы укучысы Инсафетдинов Эмиль "Казан киләчәге минем кулда" исемле үзе язган шигыре белән катнашып, I урынга лаек булды һәм республика турына үтте. Уңышлар телибез!*

**Гөлмирә Батталова, 8 нче Г сыйныфы укучысы**

*Декабрь ае – инвалидлар декадасы булуы белән истә калды. Мәктәбебездә аларга багышланган чаралар үткәрелде: 1 нче декабрь көнне инвалидлар декадасының ачылу тантанасы билгеләп үтелде. Коррекцион классларда Татарстан республикасының А.Сладковский җитәкчелегендәге Дәүләт симфоник оркестры, С.Гобәйдуллина исемендәге Дәүләт симфоник оркестры музыкантлары чыгыш ясадылар.*

**Хәмидуллин Рәнис, 4 нче В сыйныфы укучысы**





*Кадерле Кыш бабай!*

*Мин Семёнова Снежана, 78 нче мәктәпнең 6 нчы М сыйныфында укыйм. Тиздән Яңа ел – минем иң яраткан бәйрәмем җитә. Кыш бабай, минем Синнән гаиләмә, туганнарыма, дусларыма сәламәтлек сорыйсым килә. Алар яхшы һәм тату яшәсеннәр. Сау бул, Кыш бабай!*

**Семёнова Снежана, 6 М**



**Әхмәтова Зәлидә, 2 В**



**Кузягина Дарья, 6 Г**

*Игелекле Кыш бабай!*

*Сиңа Фёдорова Ксения хат яза. Яңа ел бәйрәмен бик яратам. Миңа китаплар һәм бик күп кәнфитләр бүләк итүеңне көтеп калам. Бөтен кешеләргә дә саулык-сәламәтлек, бәхет телим. Сау бул, Кыш бабай!*

**Фёдорова Ксения, 6 М**

## КЫШ

Кыш җиттеме бөтен җир,
Ап-ак карга күмелә.
Кар бөртекләренә карап,
Күңелләргә нур иңә.
Табигатьнең төрлелеген
Бизи кышның көннәре.
Искиткеч матур була
Салкын, айлы төннәре.

Сокланам мин табигатьнең
Аклык, сафлыгы белән.
Кыш бүләге – шугалакта
Рәхәтләнеп ял итәм.
Кышның салкынына карап,
Уйнамый тормыйбыз без.
Чыныгырга бик тә кирәк,
Саулыкны уйлыйбыз без.

**Мәрданова Айгөл, 9 Г**

## ГАИЛӘ ҺӘМ МӘКТӘП.

Гаиләдә газиз әти-әни
Яшәргә көч бирәләр.
Кайгыртучан апа-абый,
“Дәү үс, сеңлем”,- дияләр.
Мәктәп – белем йортыбызда
Һәр көн гыйлем алабыз.

Тәртип-әхлакка өйрәнеп,
Зур кешеләр булабыз.
Гаиләдә һәм мәктәптә,
Безгә якын кешеләр бар.
Мин аларга рәхмәтлемен,
Тормышымда ярый алар бар.

**Дәминова Динә, 5 Г**





**Бряндина Арина, 5 Г**

*Кыш елның бик матур вакыты. Агачларда кар ята, елгалар ялтырап торган боз белән каплана. Кар атышып уйнарга, тауда һәм тимераякта шуарга мөмкин. Ләкин уенга алданып, салкын тидермәгез.*

**Александрова Настя, 6 Г**



**Киселёв Тимур, 2 Б**



**Шәйхиева Илнара, 4 В**

*Мин кышны яратам. Кар ява, буран уйный. Балалар да урамга чыкмыйча түзмәгәннәр. Алар тимераяк, чаңгы-чана шуалар, кар атышып уйныйлар, кар бабай ясыйлар.*

**Гущина Алина, 4 В**



78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары
тылсымлы, буранлы кыш көннәренә туры килгән туган көннәрен
билгеләп үтүче укытучыларны котлый:

*Инсафетдинова Миләүшә Тәлгәтовна*

*Хорина Нина Федоровна*

*Кофтункина Елена Валентиновна*

*Опарина Лилия Фәридовна*

*Приходько Надежда Анатольевна*

*Роганова Татьяна Николаевна*

*Гомәрова Гөлчәчәк Мөнәвировна*

*Исмаилова Люция Исраиловна*

*Яковлева Евгения Николаевна*

*Ильина Валентина Ивановна*

Котлы булсын туган көнегез,
Уңыш сездән бер дә китмәсен.
Тормыш елгалары ташып аксын,
Бәхет чишмәләре кипмәсен.




**Мөхәррирләр:** Мәрданова А., Батталова Г., Дәминова Д., Галиев Р., Гущина А., Шәйхиева И., Хәмидуллин Р., Бряндина А., Александрова Н.

**Консультантлар:** Л.И.Исмаилова, Г.М.Гомәрова

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре

Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю.Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58- 61.

E-mail: school_7878@mail.ru
S78kzn@edu.tatar.ru